3.9.1. Техник карау нәтиҗәләре буенча Идарә бүлегенең баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан техник карау узу турында түбәндәге документларның берсе рәсмиләштерелә:

техник карау узу турында таныклык (машина куркынычсызлык таләпләренә җавап биргән очракта);

техник карау акты (машина нинди дә булса куркынычсызлык таләпләренә җавап бирмәгән очраклар ачыкланганда, шулай ук әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган очракларда).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник карау уздыру көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник карау узу турында таныклык бирү турында яки техник карау акты бирү турында карар.

3.9.2. Техник карау узу турында таныклык бирү турында карар кабул ителгән очракта, техник карау узган машинаның һәм аның тагылмасының хуҗасына Идарә бүлегенең баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан әлеге таныклык бирелә.

Техник карау узу турында таныклык гамәлдә була:

пассажирлар ташу өчен билгеләнгән һәм йөртүче утыргычыннан кала 8 артык утыру урыны булган автотранспорт чараларына карата, – бирелгән көненнән башлап 6 ай дәвамында;

калган машиналарга карата – календарь елы дәвамында.

Мөрәҗәгать итүче Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына автомат рәвештә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документның электрон рәвеше җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник карау уздыру көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: машинага техник карау узу турында таныклык бирү.

3.10. Машинаның җитешсезлекләрен бетерү буенча техник карау акты бирү турында карар кабул итү очрагында, Идарә бүлегенең баш дәүләт инженер-инспекторы тарафыннан техник карау уздыруның яңа срогы билгеләнә.

Машинаның нинди дә булса куркынычсызлык таләпләренә җавап бирмәве турында белешмәләрне үз эченә алган техник карау акты рәсмиләштерелгән көннән соңгы 20 көн дәвамында машинаны кабат техник карау уздыру өчен тапшырганда, әлеге актны рәсмиләштергән Идарә бүлеге тарафыннан машинаның техник торышын тикшерү эше бары тик машинаның әлеге актта күрсәтелгән, мондый туры килмәүчәнлек билгеләнгән параметрларына карата гына уздырыла. Җитешсезлекләр бетерелгәннән соң техник карау уздыру турында таныклык бирү әлеге Регламентның 3.9 пунктына туры китереп гамәлгә ашырыла.

3.11. Гамәлдә булу чорында техник карау уздыру турында таныклык югалган яисә бозылган очракта, тиешле дубликат әлеге таныклыкны рәсмиләштергән Идарә бүлеге тарафыннан машина хуҗасының яисә аның вәкиленең гаризасы буенча, 1013 номерлы карар белән расланган кагыйдәләрнең 9 пунктында карал-

